# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең Зур Колангы поселогында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**23 нче ноябрь 2023 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 23 ноябрендә 11сәгатьтә булган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны урыны буенча Мөрәле авыл җирлеге Зур Колангы поселогы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

а) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- материаллар сатып алып, янгын гидрантларын урнаштыру;

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсъәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 18 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -11, бу 61 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 11 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенның **0** катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең Зур Колангы поселогында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны урыны буенча Мөрәле авыл җирлеге Зур Колангы поселогы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне

хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

а) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- материаллар сатып алып, янгын гидрантларын урнаштыру;

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Мөрәле авыл җирлеге Башлыгы Р.Р.Зиннатуллин